КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 октябрь г.Казань № 906

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 - 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2023 ел, 8 сентябрь, 1112 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 - 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2023 ел, 8 сентябрь, 1112 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2024 - 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» юлында «0,555341» саннарын «0,452904» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2024 - 2026 елларга донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын

тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары башкара торган дәүләт эше күләмнәрендә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» бүлегендә:

«кан донорларыннан компонентларга аертылмаган донорлар каны» юлының 5 графасында «2 152,9» саннарын «3 202,4» саннарына алмаштырырга;

«автоматик аферез ысулы белән компонентларга аертылмаган донорлар каны (плазмоферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасында «2 668,1» саннарын «1 800,0» саннарына алмаштырырга;

«тромбоцитоферез ысулы белән ком-понентларга аертылмаган донорлар каны (плазмоферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасында «1 281,0» саннарын «4 452,8» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин